МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 гыйнвар 2019 ел № М 07

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында нигезнамәне раслау хакында

Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 48 маддәсе, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.
2. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында нигезнамәне раслау хакында» 2018 елның 17 августындагы М 388 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага, Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга, Контроль-хисап палатасы рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Шәһәр Хакименең
2019 елның 10 гыйнварындагы
М 07 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә
өстәмә гарантияләр турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезнамә Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 карары нигезендә Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затларга (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) өстәмә гарантияләр бирү төрләрен, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Әлеге нигезнамәдә каралган өстәмә гарантияләр бирүгә чыгымнар ел саен, тиешле җирле үзидарә органын (муниципаль органны) карап тотуга чираттагы финанс елына шәһәр бюджеты проектын эшләгәндә, Башкарма комитет тарафыннан карала.

3. Әлеге нигезнамәдә каралган өстәмә гарантияләр бирүгә чик чыгымнар ел саен Шәһәр Советының чираттагы финанс елына шәһәр бюджеты турында карары белән билгеләнә.

4. Әлеге нигезнамә белән муниципаль хезмәткәрләргә түбәндәге өстәмә гарантияләрне бирү тәртибе һәм шартлары билгеләнә:

1) торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия;

2) авыруларны стационарда дәвалаганнан соң санаторийда дәвалау кирәклегенә бәйле рәвештә, санаторий-курортта дәвалану өчен юлламаның (алга таба – санаторий-курортта дәвалану өчен юллама) бәясен түләү;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә, иминият пенсиясен алуга хокукы булганда, биләгән вазыйфасыннан азат ителгәндә һәм эштән җибәрелгәндә бер тапкыр түләү.

2 бүлек. Торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган
субсидияне бирү тәртибе һәм шартлары

5. Муниципаль хезмәткәргә торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия (алга таба – бер тапкыр бирелә торган субсидия) бер үк вакытта түбәндәге шартлар булганда бирелә:

1) элек түләнгән бер тапкыр бирелә торган субсидиянең булмавы;

2) муниципаль хезмәткәрнең, әлеге нигезнамәнең 7 пунктында каралган документларны теркәп, бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында гариза (алга таба – гариза) бирүе;

3) Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль

органнарда) бер елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы булу;

4) торак хокуклары объектларында муниципаль хезмәткәр гаиләсенең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең тулаем дәрәҗәсе муниципаль хезмәткәр гаиләсенең бер әгъзасына гомуми торак мәйданының 15 квадрат метрдан ким булу яки билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган бүлмәдә яшәү;

5) бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында гариза биргәнгә кадәр биш ел эчендә, муниципаль хезмәткәр һәм (яки) аның гаилә әгъзалары тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең торак шартларын начарайтуга китергән торак бүлмәләр белән гражданлык-хокукый характердагы килешүләр башкарылмау.

6. Әлеге нигезнамә максатларында муниципаль хезмәткәрнең гаилә әгъзалары дигәндә, аның белән бергә яшәүче балалары, ата-анасы, ире (хатыны), муниципаль хезмәткәрнең бертуган абыйлары һәм бертуган апалары дип аңларга кирәк.

7. Муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турындагы мәсьәләне карау өчен муниципаль хезмәткәр:

1) әлеге нигезнамәнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча тиешле җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе исеменә гариза бирә;

2) әлеге нигезнамәнең 2 нче кушымтасында каралган форма буенча барлык кирәкле мәгълүматларны күрсәтеп анкета тутыра;

3) түбәндәге дәлилләүче документларны бирә:

- муниципаль хезмәткәрнең бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажын дәлилләүче хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

- муниципаль хезмәткәрнең торак бүлмәсенә хокук билгеләүче документлар күчермәсе (приватизация килешүе, сатып алу-сату килешүе, бүләк итү килешүе, наем килешүе, ордер һәм башкалар);

- муниципаль хезмәткәрнең аның гаилә әгъзалары белән туганлык мөнәсәбәтләрен дәлилләүче документларның күчермәләре (язылышу турында таныклык, туу турында таныклык);

- компетентлы органның (вазыйфаи затның) муниципаль хезмәткәрнең торак бүлмәсен яшәү өчен яраксыз дип тану турында хокукый актының күчермәсе (торак бүлмә яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта).

8. Әлеге нигезнамәнең 5 пунктында каралган нигезләр булганда, тиешле җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында Яр Чаллы шәһәре Хакиме адресына юллама (алга таба – юллама) җибәрә.

9. Гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча комиссия (алга таба – комиссия) тарафыннан юллама алынган көннән башлап бер ай срокта гамәлгә ашырыла.

Комиссияне, аның составын һәм эш регламентын формалаштыру тәртибе, шулай ук комиссия әгъзаларының җаваплылыгы Яр Чаллы шәһәре Хакиме тарафыннан билгеләнә.

10. Гариза һәм аңа теркәлгән документлар алынганнан соң бер ай эчендә комиссия:

1) әлеге нигезнамәнең 7 пункты нигезендә, гаризага теркәлгән документларның булуын тикшерә;

2) бирелгән документларда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген

тикшерә;

3) әлеге нигезнамәнең 5 пункты нигезендә, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагучы хәлләрнең булуын билгели;

4) муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү яки бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул итә.

11. Бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү яки бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагу турындагы карар комиссия тарафыннан әлеге нигезнамәнең 3, 4 пунктларында каралган форма буенча кабул ителә.

12. Муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге нигезнамәнең 5 пункты нигезендә, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагучы хәлләрнең булуы;

2) документларда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеккә туры килмәве;

3) әлеге нигезнамәнең 7 пунктында каралган документларның бирелмәве яисә аларда төгәлсезлекләр булу.

13. Әлеге нигезнамәнең 12 пунктында каралган нигезләр булмаганда, комиссия муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында карар кабул итә.

14. Комиссия квартал саен, бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турында карар кабул итүгә мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәрләрнең исемлеген (алга таба – исемлек) формалаштыра һәм аны раслау өчен шәһәр Хакименә җибәрә.

15. Шәһәр Хакиме тарафыннан расланган исемлекләр нигезендә Башкарма комитетның финанс идарәсе (алга таба – финанс идарәсе), элек расланган исемлекләрне исәпкә алып, бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турында карар кабул итүгә мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм исемлеген (алга таба – бердәм исемлек) формалаштыра.

16. Түбәндәге нигезләрнең берсе булганда, муниципаль хезмәткәр бердәм исемлектән төшереп калдырыла:

1) әлеге нигезнамәнең 5 пункты нигезендә, бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү шартларын югалту;

2) вазыйфаи затларның комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында карар кабул итү өчен нигез булып хезмәт иткән хокуксыз гамәлләре ачыклану;

3) Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) муниципаль хезмәтнең туктатылуы;

4) муниципаль хезмәткәр тарафыннан бердәм исемлектән чыгару турында гариза бирелү.

17. Муниципаль хезмәткәрне бердәм исемлектән чыгару комиссия тәкъдиме буенча шәһәр Хакиме карары белән башкарыла.

18. Муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган субсидияләр, аларның бердәм исемлектә урнашкан чираты буенча, чираттагы финанс елына шәһәр бюджетында бу максатларга каралган акчалар чикләрендә бирелә.

19. Бирелә торган субсидиянең күләме түбәндәге формуладан чыгып билгеләнә:

С = (НП – УН) × НС × К, монда:

С – бер тапкыр бирелә торган субсидиянең күләме;

НП – Шәһәр Советының «Торак бүлмә бирү нормасын һәм исәпкә алу нормасын билгеләү турында» 2006 елның 10 мартындагы 9/7 нче карары белән расланган социаль наем килешүе буенча торак мәйдан бирү нормасы;

УН – Шәһәр Советының «Торак бүлмә бирү нормасын һәм исәпкә алу нормасын билгеләү турында» 2006 елның 10 мартындагы 9/7 нче карары белән расланган социаль наем килешүе буенча торак мәйдан бирүне исәпкә алу нормасы;

НС – Яр Чаллы шәһәрендә 1 кв.м. торак бәясе нормативы;

К – Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) гомуми муниципаль хезмәт стажыннан чыгып билгеләнә торган төзәтү коэффициенты:

| гомуми муниципаль хезмәт стажы | 1-3 ел | 3-6 ел | 6-9 ел | 9-12 ел | 12-15 ел | 15 -18 ел | 18 һәм аннан күбрәк ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| төзәтү коэффициенты | 0,1 | 0,2 | 0,3 | 0,5 | 0,7 | 0,9 | 1 |

## 3 бүлек. Муниципаль хезмәткәргә санаторий-курортта дәвалану өчен юллама бәясен түләү тәртибе һәм шартлары

20. Муниципаль хезмәткәргә санаторий-курортта дәвалану өчен юллама бәясен түләү, сәламәтлек саклау учреждениесеннән бирелгән тиешле медицина бәяләмәсе булганда, аның бәясе күләмендә, ләкин ул биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасының бер окладыннан артмаган күләмдә башкарыла.

21. Санаторий-курортта дәвалану өчен юллама бәясен түләү тиешле җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенең муниципаль хезмәткәр гаризасы буенча кабул иткән карары нигезендә, ике елга бер тапкыр башкарыла. Санаторий-курортта дәвалану өчен юллама бәясен түләү турындагы гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

1) стационарда дәвалаганнан соң санаторийда дәвалану кирәклеге турында сәламәтлек саклау учреждениесенең бәяләмәсе;

2) санаторий-курортта дәвалану өчен юллама бәясен дәлилләүче документлар.

## 4 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының (муниципаль органнарның) муниципаль хезмәткәрләренә, иминият пенсиясен алуга хокукы булганда, биләгән вазыйфасыннан азат ителгәндә һәм эштән җибәрелгәндә бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары

22. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының (муниципаль органның) муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү), иминият пенсиясен алуга хокукы булганда, биләгән вазыйфасыннан азат ителгәндә һәм эштән җибәрелгәндә гамәлгә ашырыла.

23. Иминият пенсиясен алуга хокукы булганда, биләгән вазыйфасыннан азат итү һәм эштән җибәрү дигәндә, «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә иминият пенсиясе алуга

хокук бирә торган нигезләр буенча муниципаль хезмәттән азат итү дип аңларга кирәк.

24. Муниципаль хезмәткәр иминият пенсиясен алуга хокукы булганда, биләгән вазыйфасыннан азат ителгән һәм эштән җибәрелгән очракта, аңа бер тапкыр бирелә торган түләү, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алуга кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) 5 елдан ким булмаган хезмәт куйганда, түбәндәге коэффициентларны исәпкә алып башкарыла:

| Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү елы | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел һәм аннан соңгы еллар | Муниципаль хезмәт стажын исәпкә алу коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Минималь муниципаль хезмәт стажы | 16 ел | 16 ел 6 ай | 17 ел | 17 ел 6 ай | 18 ел | 18 ел 6 ай | 19 ел | 19 ел 6 ай | 20 ел | 5 |
| | 19 ел | 19 ел 6 ай | 20 ел | 20 ел 6 ай | 21 ел | 21 ел 6 ай | 22 ел | 22 ел 6 ай | 23 ел | 7 |
| | 21 ел | 21 ел 6 ай | 22 ел | 22 ел 6 ай | 23 ел | 23 ел 6 ай | 24 ел | 24 ел 6 ай | 25 ел | 9 |
| | 26 ел | 26 ел 6 ай | 27 ел | 27 ел 6 ай | 28 ел | 28 ел 6 ай | 29 ел | 29 ел 6 ай | 30 ел | 10 |

* Тиешле елда минималь муниципаль хезмәт стажы Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексына кушымта нигезендә билгеләнә.

25. Бер тапкыр бирелә торган түләүнең күләме муниципаль хезмәткәр стажын исәпкә алган коэффициентны эштән азат ителгән көнгә исәпләнә торган айлык акча күләменә тапкырлау юлы белән билгеләнә.

26. Бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгару муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттән киткән көненә һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

27. Бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык хезмәт хакы составына түбәндәгеләр кертелә:

1) вазыйфаи оклад;

2) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) классны чин өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

4) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

5) аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләр үтәгән өчен премияләр;

6) айлык акчалата бүләкләү;

7) ел саен бирелә торган түләүле ялга киткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләменең 1/12 өлеше;

8) нормага салынмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләве;

9) төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый акт проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый акт проектларын әзерләү һәм

редакцияләү һәм аларны юрист яки югары юридик белемгә ия башкаручы сыйфатында визалау кергән муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләү (юридик хезмәт өчен түләү);

10) профильле фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

11) Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

12) дәүләт сере булып саналган мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә.

28. Бер тапкыр бирелә торган түләү, җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесенең бер тапкыр бирелә торган түләү турындагы хокукый акты нигезендә, муниципаль хезмәткәр белән ахыргы исәп-хисап ясалганда башкарыла.

29. Бер тапкыр бирелә торган түләү бер тапкыр башкарыла. Иминият пенсиясен алу хокукы булганда биләгән вазыйфасыннан азат ителгән һәм эштән җибәрелгән һәм алга таба муниципаль хезмәте туктатылган граждан муниципаль хезмәткә алынган очракта, аңа бер тапкыр бирелә торган түләү башкарылмый.

## 5 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

30. Әлеге нигезнамәдә каралган өстәмә гарантияләрне финанс ягыннан тәэмин итү мөмкинлеген кире кагуга нигезләр булган очракта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы карары белән әлеге нигезнамәнең яисә аның аерым өлешләренең гамәлдә булуы туктатылырга мөмкин.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә
гарантияләр турында нигезнамәгә
1 нче кушымта

______________________________________________
жирле үзидарә органы (муниципаль орган) житәкчесе
вазыйфасының тулы исеме

______________________________________________
Фамилиясе И. А.и. юнәлеш килешендә

______________________________________________
муниципаль хезмәт вазыйфасының тулы исеме

______________________________________________
(жирле үзидарә органын (муниципаль органны) күрсәтеп),

______________________________________________
Фамилиясе И.А.и. иялек килешендә

Гариза

Торак хокуклары объектларында минем гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең тулаем дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына гомуми торак мәйданының 15 квадрат метрдан ким булу/ мин һәм минем гаилә әгъзалары билгән торак бүлмә яшәү өчен яраксыз дип танылу сәбәпле *(кирәгенең астына сызарга),* миңа торак _________________ өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне сорыйм.
сатып алу/ төзү

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча комиссия тарафыннан тиешле органнарда әлеге гаризада һәм аңа теркәлгән документларда күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүгә ризалык бирәбез.

Әлеге гаризада һәм аңа теркәлгән документларда күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә, алар турында бер ай срокта торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча комиссиягә хәбәр итәргә йөкләмә алам.

Теркәлә:
1. ______________________________________________;
2. ______________________________________________;
3. ______________________________________________;
4. ______________________________________________;
5. ______________________________________________.

Муниципаль хезмәткәр: ________________
имзасы

Хокукка сәләтле
гаилә әгъзалары:
1. ______________________________________________;
2. ______________________________________________;
3. ______________________________________________;
4. ______________________________________________;
5. ______________________________________________.
гаиләнең хокукка сәләтле барлык әгъзаларының фамилияләре И.А.и. һәм имзалары

«___» _____________ 20___

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә
гарантияләр турында нигезнамәгә
2 нче кушымта

# АНКЕТА

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме
______________________________________________________________________________

2. Яшәү урыны адресы: _______________________________________________________
______________________________________________________________________________
өй тел.__________________ эш тел.__________________.

3. Паспорт сериясе ________ номеры _____________________ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән ________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

4. Муниципаль хезмәт вазыйфасы ____________________________________________
______________________________________________________________________________

5. Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында (муниципаль органнарда) гомуми муниципаль хезмәт стажы ___________ ел.

6. Минем белән бергә яшәүче минем гаилә әгъзаларының саны _________________________

7. Мин һәм минем белән бергә яшәүче минем гаилә әгъзалары милек хокукында гомуми мәйданы _________________ кв.м., торак мәйданы _________________ кв.м булган түбәндәге торак мәйданны (өлешне) биләп торабыз:
Мин:_______________________________________________________________________;
нинди, кайда, нигезләре
Минем гаилә әгъзалары:
1)_________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________;
2)_________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________;
3)_________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________.
Фамилиясе И.А.и. (туганлык дәрәҗәсе): нинди, кайда, нигезләре

8. Мин һәм минем белән бергә яшәүче минем гаилә әгъзалары наем килешүе (ордер) буенча гомуми мәйданы _________________ кв.м., торак мәйданы _________________ кв.м. булган торак бүлмәне биләп торабыз.

9. Мин һәм минем белән бергә яшәүче минем гаилә әгъзалары биләгән торак бүлмә яшәү өчен яраксыз дип танылды ____________________________________________________
танылмады/ компетентлы органның (вазыйфаи затның)
______________________________________________________________________________
торак бүлмәне яшәү өчен яраксыз дип тану турында хокукый актының исеме, реквизитлары

10. Минем тарафтан торак алу яки сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында гариза бирелгәнгә кадәр биш ел эчендә, минем һәм минем гаилә әгъзалары тарафыннан минем торак шартларын начарайтуга китергән торак бүлмәләр белән гражданлык-хокукый килешүләр башкарылмады.
11. Торак сатып алу һәм төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия миңа элек бирелмәде.

Әлеге анкетадагы мәгълүматларның күрсәтелгән датага дөрес һәм төгәл булуын раслыйм.

Муниципаль хезмәткәр: ______________________________________________________________.
имзасы Фамилиясе Исеме Атасының исеме

«____» _____________20__ел

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә
гарантияләр турында нигезнамәгә
3 нче кушымта

Торак сатып алу яки төзү өчен муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча
комиссия

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында нигезнамәнең 10 пункты нигезендә, ______________________________________________
_____________________________________________________________________________
муниципаль хезмәткәр вазыйфасының тулы исеме, Фамилиясе И А.и
торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында гаризасын караганнан соң, комиссия билгеләде:

1. ________________________ һәм аның гаилә әгъзалары түбәндәге адрес буенча яши:
муниципаль хезмәткәрнең Фамилиясе И.А.и
_____________________________________________________________________________,

билгеләнгән торак бүлмәнең гомуми мәйданы _____________кв.м.ны тәшкил итә,
билгеләнгән торак бүлмәнең торак мәйданы _______________кв.м.ны тәшкил итә.

2. Торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия ___________________________ бирелмәгән.
Фамилиясе И.А.и.

3. ________________________________________________ Яр Чаллы шәһәренең җирле
Фамилиясе И.А.и.
үзидарә органнарындагы (муниципаль органнардагы) муниципаль хезмәт стажы _________ елны тәшкил итә.

4. ________________________________________________ гаиләсенең бер әгъзасының
Фамилиясе И.А.и.)
гомуми мәйдан белән тәэмин ителешенең тулаем дәрәҗәсе _________ кв.м.ны тәшкил итә.

_____елның «____» __________ ______санлы карары белән ____________________________
Фамилиясе И.А.и.
билгеләнгән торак бүлмә яшәү өчен яраксыз дип танылды *(торак бүлмә яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта күрсәтелә)*

5. ___________________________________ торак сатып алу һәм төзүгә субсидия бирү
Фамилиясе И.А.и.)
турында гариза язганга кадәр биш ел эчендә, аның торак шартларын начарайтуга китергән килешүләр гамәлгә ашырылмады.

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турындагы Нигезнамәнең 13 пункты нигезендә Комиссия карар бирде:

1. ___________________________________ торак сатып алу һәм төзү өчен бер тапкыр
(Фамилиясе И.А.и.)

бирелә торган субсидияне ______________ сум күләмендә бирергә.

2. ________________________ торак сатып алу һәм төзү өчен бер тапкыр бирелә торган
(Фамилиясе И.А.и.)

субсидия бирү турында карар кабул ителүгә мөнәсәбәтле муниципаль хезмәткәрләр исемлегенә кертергә.

Комиссия рәисе ____________________ ____________________
имза И.А.и. Фамилиясе

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә
гарантияләр турында нигезнамәгә
4 нче кушымта

Торак сатып алу яки төзү өчен муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган субсидияләр бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча
комиссия

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында нигезнамәнең 12 пункты нигезендә, ________________________________________________

________________________________________________________________________
муниципаль хезмәткәр вазыйфасының тулы исеме, Фамилиясе И А.и
торак сатып алу яки төзү өчен бер тапкыр бирелә торган субсидия бирү турында гаризасын караганнан соң, комиссия карар бирде:

________________________________________________________________________
Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр турында
________________________________________________________________________
нигезнамәнең 12 пункты нигезендә бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагу
________________________________________________________________________
сәбәбен күрсәтергә
сәбәпле, ____________________бер тапкыр бирелә торган субсидия бирүне кире кагарга.

Комиссия рәисе ___________________ ____________________
имза И.А.и. Фамилиясе